Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LII – 3**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 25 августы

“Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге XLI-3 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Коррупциягә каршы тору эшчәнлеген камилләштерү максатларында һәм “Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 22 декабрендәге 431-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы Указы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге XLI-3 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) пунктта:

“д” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“д) “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсендәге 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 маддәсе нигезендә җирле үзидарә органына коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмага җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый шартнамә төзү турында, әгәр әлеге оешма муниципаль идарәсенең аерым функцияләре аның җирле үзидарә органында вазыйфасын биләгән вакытта башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, хәбәрнамә килеп ирешү шундый шартларда, күрсәтелгән гражданга элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләренә керүдән баш тарткан очракта яисә мондый гражданга коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфасын биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирү турындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан каралмаган булса.”;

б) 22 пунктта:

өченче һәм дүртенче җөмләләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль хезмәткәр (аның вәкиле) комиссия утырышына килмәгән очракта һәм муниципаль хезмәткәрнең әлеге мәсьәләне карау турында язма үтенече булмаганда, аның катнашыннан башка бу мәсьәләне карау кичектерелә. Муниципаль хезмәткәр җитди сәбәпләрсез кабат килмәгән очракта, комиссия әлеге мәсьәләне муниципаль хезмәткәрдән башка гына  карау турында карар кабул итәргә мөмкин.";

түбәндәге эчтәлектәге җөмләне өстәргә:

“Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан (аның вәкиле) комиссиясе утырышына килмәгән очракта, күрсәтелгән граждан яшәү урынын алмаштырган һәм комиссия утырышын уздыру датасы турында аңа мәгълүмат бирү буенча барлык чаралар күрелгән очракта, комиссия әлеге мәсьәләне күрсәтелгән граждан булмаганда карау турында карар кабул итәргә мөмкин.”;

в)30 пунктта

“14 пунктның “а”, “б” һәм “г” пункчаларында”  сүзләрен  “14 пунктның “а”, “б” , “г” , “д” пункчаларында”  сүзләренә  алмаштырырга;

“25 - 28  һәм  29 пунктлары белән” сүзләрен “25 – 29 һәм  31 пунктлары белән” сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                                                  И.Г.Вәлиев